# ГАЛИ ЧОКРЫЙ МИРАСЫ

## Гали Чокрый нәселе

Быел татар халкының күренекле улы, олы фикер иясе һәм руханые, мәгърифәтче әдибе Мөхәммәдгали Габдессалих улы Киековның тууына 185 ел. Татар һәм башкорт тарихларында Гали Чокрый исеме белән мәгълүм мөхтәрәм бу зат 1826 елда элеккеге Уфа губернасы Бөре өязе Тәтешле волосте (хәзерге Башкортстанның Тәтешле районы) Иске Чокыр авылы мулласы Габдессалих гаиләсендә дөньяга килә. Бу нәселнең егерменче буынга кадәрге шәҗәрәсе билгеле: Мөхәммәдгали Габдессалих улы, Габдулла улы, Шәриф улы, Киек улы, Күчүгән улы, Бырак улы, Исән улы, Дәүләтбай улы, Дәүләтъяр улы, Ходаяр улы, Ходайкол улы, Дөрмән би улы, Колман би улы, Чулман би улы, Абдал би улы, Әхмәдшәех би улы, Каратабын (Кара Газиз) би улы, Болгаер би улы, Иләк би улы, Майкы би улы. Төп чыгышлары тарихта билгеле зат – Чыңгыз ханның күренекле әмирләреннән саналган Уйшин Майкы бигә барып тоташа.

Бу нәселгә нигез салган әлеге зат турында ниләр мәгълүм соң? Майкы би хакында беренче хәбәрләр XIII-XIV гасырлар аралыгында яшәгән тарихчы Рәшидеддин Фәзлуллаһның (1247-1318) фарсы телендә язылган «Җамигъ эт-тәварих» (*«Тарихлар җыентыгы»*) исемле китабында урын алган. Биредә әлеге шәхес Һушидай Байкы исеме белән телгә алына һәм һушин исемле бер төрки кабиләнең әмире дип күрсәтелә. Мондагы мәгълүматлардан Чыңгыз ханның хәрби каһарман буларак күтәрелеп китүендә Майкы бинең дә роле шактый зур булуы сизелә. Чыңгыз хан Уйшин Майкы бине яраткан олы улы Җучига бирелгән мең кешелек гаскәр башлыгы итеп билгели. Соңрак ул, бу хезмәтеннән баш тартып, үз урынына җөрьят кабиләсе кешесе Илдекине гаскәр җитәкчесе итеп калдыра.

Әлеге шәхес хакында Гали Чокрый үзе болай дип искәртә: «Безнең төп бабамыз Майкы би Чыңгыз хан берлә бер заманда булган кеше диеб риваять кыйлалар вә һәм аның вәзирләре җөмләсендә булып, бер арбага ултырып йөргән диеб сөйлиләр вә һәм уйлы-хисаплы булган сәбәпле Уйшин Майкы би диеб ләкаб *(исем)* табкан диеб сөйлиләр. Чыңгызның мәшүәрәтләренә *(киңәшләренә)* яраган ирмеш, диләр».

Майкы би варисларыннан Киек улы Шәриф тә тарихта шактый мәгълүм шәхес. Аның исеме 1755 елда Идел-Урал буйларында кабынып киткән татар-башкорт күтәрелеше җитәкчесе Батыршаның (Габдулла Баһадиршах Гали улы, 1715-1762) патшабикә Елизавета Петровнага язган хатларында да искә алына.

Шәриф старшина дәрәҗәсендә ихлас күңелдән патшага хезмәт иткән, Уфа вакыйгасында Пугачевка каршы сугышкан һәм 1774 елда, әлеге хезмәте өчен, аңар патшабикә Екатерина тарафыннан медаль, прапорчиклык дәрәҗәсе һәм дворянлык титулы бирелгән .

Алга таба бу нәсел кешеләре, феодаллар сыйфатында җир биләмәләренә генә хуҗа булып калмыйча, акрынлап руханиларга да әйләнә баралар. Габдулланың улы Габдессалих (1798-1849) инде иген игү, умарта, тегермән тоту белән бергә, авылда муллалык иткән, ишанлык эшләрен дә башкарган. Аның тормыш-көнкүреше турында Морад Рәмзи бер хезмәтендә болай дип искәртә: «Габдессалих бине Габдула бине Шәриф ибне Киек муллалыкны Габденнасыйр бине Торымтайдан, ә суфичылык гыйлемнәрен шәех Рәхмәтулла ибне Габдустан алган. Ул Уфа вилаятенең Бөре өязендәге Иске Чокыр авылында гомер иткән, бу төбәк руханиларыннан аермалы буларак, мул тормышта яшәгән, үз кәсебе, бигрәк тә умарталыгыннан килгән керем хисабына көн күргән. Бик зур байлыкка ия булып, үз хисабына мәдрәсә тоткан...» [451].

## Тәрҗемәи хәле

Габдессалихның дүрт хатыны, алардан алты ир һәм җиде кыз баласы булган. Ул улы Галине бик яшьли уку-язуга, һөнәргә өйрәткән. Ага-сеңелләре арасында Гали үзенең зирәклеге, чаялыгы, белемгә омтылучанлыгы белән аерылып торган. Гарәп, фарсы, төрки

телләреннән тәүге сабакларны, дини һәм дөньяви фәннәрдән башлангыч гыйлемнәрне булачак шагыйрь әти-әнисеннән алган.

Хода, йә, рәхмәт әйлә эткәемә,
Ризалык бир аңа һәм әнкәемә...
Алар өч-дүрт яшемдә тәгълим итте,
«Иман» тәлкыйн итеп, тәкрим итте
*(«Иман» ятлатып, хөрмәткә өйрәтте),–*

дип яза шагыйрь бу хакта.

Гали Чокрый Бөре һәм Минзәлә өязләрендәге Чокыр, Йөгәмеш, Казанчы, Борай, Гайнә, Тайсуган, Пермь губернасы Осы өязендәге Танып авыллары мәдрәсәләрендә белем ала. Алга таба гыйлем эстәү максаты аны Эстәрлебаштагы Мөхәммәдхарис Биктимеров мәдрәсәсенә алып килә. Белемгә сусаган яшь егетнең нәкъ шушы мәдрәсәгә килеп чыгуы бер дә гайре табигый хәл түгел. Бу вакытта Гали Чокрыйга егерме яшь була.

Эстәрлебаш мәдрәсәсен тәмамлагач, Гали Чокрый, әлеге уку йорты җитәкчеләренең үтенече белән, шунда эшкә кала. Биредә берникадәр вакыт шәкертләр укытканнан соң, туган якларына әйләнеп кайта, Диния нәзарәтеннән рөхсәт кәгазе алып, Иске Чокырда муллалык итә башлый.

Гали Чокрыйның туган якларына әйләнеп кайтуына инде әти-әнисе – дөнья куйган, ә ата малы өйдәге варислар тарафыннан үзара бүленеп беткән була. Ул, имам булырга теләп, ике еллап указ артыннан йөри. Үз максатына ирешкәннән соң, авылда мәдрәсә ачып, шәкертләр тәрбияләү эшенә керешә, шул ук вакытта әдәби иҗат эше белән дә шөгыльләнә.

Истәлекләрдән күренгәнчә, Гали Чокрый киң карашлы, зирәк, туры һәм тапкыр сүзле кеше булган. Аның шушы сыйфатлары үз тирәсендәге кайбер кешеләргә ошамаган күрәсең. Алар, шагыйрьгә каршы коткы таратып, аның һәр кылган гамәленә аяк чалып торганнар. Хәтта бу дошманлык тирә-яктагы утыз ике мулланың имзасы белән «аның каны хәләл, катле ләзим» дип, Диния нәзарәтенә шикаять язып бирүгә кадәр барып җитә. Шагыйрь моның аркасында шактый күп җәфалар күрә. Соңрак болар барысы бергә аның иҗатында хөсетлек, явызлык кебек тема-мотивларның вакыт-вакыт кискен яңгыраш алуына сәбәп була. Әдип, үзенә дошман булганнарны искә алып, «Дөрре Гали» *(«Гали энҗеләре»)* шигырендә болай дип яза:

Кәримнәр фәйзына тоттым күземне,
Ләимнәр таптады һәр дәм үземне...
*(Изгеләр тарафына тоттым күземне,*
*Начарлар таптады һәрчак үземне...)*

Әдип яшь чагында ук Шыгай авылы (хәзерге Сарман районында) мулласы Мәүләви Җәлаледдин Борһанеддин улының Мәрфуга исемле кызына өйләнә, аның белән бергә өч кыз һәм биш ир бала тәрбияләп үстерә. Уллары Гатаулла, Гыйниятулла (Ахунҗан), Зарифҗан, Һади, Гарифулла исемле. Болардан өчесе – Гатаулла, Гыйниятулла, Гарифулла ата-бабалары традицияләренә тугрылык саклап, заманының укымышлы кешеләре булып танылалар. Олы улы Гатаулла Иске Чокыр авылыннан күчеп Ирәктедә мулла булып торган. Гыйниятулла туган авылында атасы башлап җибәргән изге эшләрне дәвам иткән.

Төпчек угыл Гарифулла да ата-ага юлыннан читләшми, үз чорының күренекле рухание һәм мәгърифәтчесе булу белән бергә иҗат эше белән дә актив шөгыльләнә. Гарифулла Чокрый-Киеков атасының иҗат мирасын туплау, күчерү өлкәсендә дә шактый эш башкара. Гали Чокрый әсәрләренең исән-имин безнең көннәргә кадәр килеп җитүендә аның өлеше бихисап зур.

Гали Чокрыйның тормыш сәхифәләренә ныграк игътибар иткән саен, аның эш-хәрәкәт, гамәл кешесе икәнлеге ачык аңлашыла. Ул гомеренең күпчелек өлешен, мәгариф эшенә – мәктәп-мәдрәсә ачып, балалар укытуга багышлый, дүрт тапкыр (1872, 1879, 1880, 1886 елларда) хаҗ кыла, иҗат эше белән дә актив шөгыльләнә, язганнарын китап итеп бастыра.

Гали Чокрый суфичылыкның нәкышбәндия тарикате вәкиле буларак мәгълүм. Ул үз гомерендә бу тарикатьтә дүрт шәехкә мөрид булып торган. Беренче остазы, атасы Габдессалих ишан, Галине кечкенә вакытыннан ук тасаувыф юлында тәрбияләргә омтыла. Бу хакта шагыйрь үзенең «Игъзаре Галийә шөкернамәи Галийә» (*«Галинең җавабы яки рәхмәт шигыре»*) исемле әсәрендә болай дип искә ала:

Биш-алты йәшем заманда, тегермәнгә сәбәб берлә,
Барыб кундык атам берлә тегермән саклаеб сәрпай *(баштанаяк)*...
Чөн алдым дәрес әсрари, гыйнәйәт *(ярдәм)* әйләде Бари *(Алла)*,
Биш йәшдән булыб йари, зикер чалыр идем сәрпай *(баштанаяк)*.

Үсә төшкәч, атасыннан алган башлангыч гыйлемнәр Галигә суфичылык тәгълиматы белән якыннанрак танышырга мөмкинлек бирә. Яшь егет, берникадәр вакыт Урта Азия якларыннан бу тарафларга килеп чыккан шәех Мөхәммәд Морад Бәдәхшанига мөрид була, аның җитәкчелегендә тасаувыф серләренә төшенә.

Кем соң ул Морад Бәдәхшани? Без аның турынданиләр әйтә алабыз? Кызганыч ки, безнең көннәргә әлеге шәхес хакында мәгълүматлар бик аз килеп җиткән. Шулай да Гарифулла Чокрыйның алда искә алынган «Гайн әр-риза...» кульязмасыннан аның суфичылык силсиләсе Мөхәммәдҗан бине Габдеррахман әл-Мәкки, Шаһ Гуләм Гали Дәһләви аркылы нәкышбәндия тарикатенең мөҗәддидия тармагына нигез салган мәшһүр суфи Әхмәд Фаруки Сирхиндигә (Имам Раббани, 1564-1624) барып тоташуы мәгълүм.

Гарифулла Чокрый шәех Бәдәхшани турында болай дип яза: «Мәзкүр Мәхәммәд Морад Бәдәхшани хәзрәтләре үзенең мөридләре арасында айлап-еллап йөрер иде... вә һәм фил хакыйкати *(чынлыкта)* нәфс әл-әмердә әзкийәләрдән *(изгеләрдән)* булуы шиксез заһир *(билгеле)* иде. Кешене йахшы таныр иде. Бик йахшы шигырьләр әйтер иде. Бер хикәйәтне шигырь берлә сөйләргә теләсә нәзым кылырга кадир *(оста)* иде. Үзене Шәех Дәйри диеб тәхәллүс кылыр *(атар)* иде». Бу мәгълүматлар Гали Чокрыйның шагыйрь булып китүендә Мөхәммәд Морад Бәдәхшаниның да роле шактый зур булган дип фаразларга нигез бирә[1].

Шәех Мөхәммәд Морад Бәдәхшани да, күпчелек нәкышбәнди шәехләрдән аермалы буларак, үз өйрәтүләрендә тавышлы зикердән файдаланган. Гали Чокрый күңеле белән тавышлы зикерне кабул итә алмый, шул сәбәпле ул, туган якларын ташлап, Эстәрлебаш мәдрәсәсенә килә һәм егерме бер яшенә чаклы заманында Ниязколый әт-Төркмәни әл-Бохарида (1821 елда үлгән) белем алган Мөхәммәдхарис Биктимеров (1870 елда үлгән) җитәкчелегендә укуын дәвам итә.

Гали Чокрыйның дүртенче остазы – алда искә алынган Әхмәд Фаруки Сирхиндинең варисы, нәкышбәндиле сахибзадә Мөхәммәд Мәзһар Әфәнде. Чокрый хаҗ сәфәрләренең берсендә Мәдинә шәһәрендә әлеге шәех белән очраша, аннан «котбе җиһан» *(«җиһан үзәге»)* дәрәҗәсе һәм «хәдим әл-фукара» *(«фәкыйрьләр хезмәтчесе»)* исемен, иҗазәтнамә ала. Әдәбият тарихында Мөхәммәд Мәзһар Әфәнденең Гали Чокрыйдан кала Габдерәшид Ибраһимов, Морад Рәмзи кебек татар укымышлыларына да рухи остаз булуы мәгълүм.

Хаҗ сәфәреннән туган якларына әйләнеп кайтканнан соң, Гали Чокрый үз ханәкәсен төзеп, мөридләр тәрбияләү эшенә керешә. Бу хакта әдәбият галиме Гали Рәхим болай дип яза: «Гади көннәрдә аның мәхәллә мәчетендә бер данә булсын намаз укучы булмаганы хәлдә, җомга көннәрдә читтән йөз-йөз илле кадәр мөрид җыелып, зикер мәҗлесләре ясыйлар икән. Соңга таба бу мәҗлесләр Иске Чокырдан аерылып чыгып утырган Күрдем исемле авыл янындагы урманда, Гали Чокрыйның умарта бакчасында ясала башлаган. Элек анда кабыктан бер куыш кына ясалган булса да, соңыннан бу урында тактадан мәчет тә корылган... Ишанның мөридләре булган ирләр һәм хатыннар шунда җыелып,

[1] Шиһабеддин Мәрҗанинең "Мөстафад әл-әхбар..." китабында авторны мактап шигырьләр язучы Габдеррахман бине Давыт Чутаи, Ихсан бине Гомәр Мәмсәви, Фәхреддин бине Арслан Бүкәли, Габдулла Бәләбәи-Раи әсәрләре белән бергә Габделкаюм бине Морад Бәдәхши исемле кешенең дә мәдхиясе басылган. Морад Бәдәхшани һәм Габделкаюм бине Морад Бәдәхшинең бер үк шәхес булуы да мөмкин.

...мәҗлесләр корып яталар икән. Бу бакчаны үзләре «бостане хаҗи» дип атаганнар. Андагы чишмәне изге вә шифалы дип, игътикад (*ышаныч*) кыла башлаганнар» [209].

Гарифулла Чокрый сүзләренә караганда, әлеге умарта бакчасында Гали Чокрыйның шәкертләре, зикер чалу белән бергә, җыелышып мөнәҗәтләр әйткәннәр, шигырьләр укыганнар, шул рәвешле бу бакчаны әдәби мәҗлесләр үткәрү урынына әверелдергәннәр. Бу турыда ул бер кулъязмасында болай дип искәртә: «Ошбу сөхбәте кобрәидә *(олы мәҗлестә)* укылган бәетләрнең беразы вә һәм сөхбәте кобрәи соңында бу сөхбәтне яд кыйлып *(искә алып)* назым улынмыш бәетләрнең беразы бу дәфтәрдә соңрак язылса кирәктер».

Остазларының шагыйрьлек сәләте шәкертләренә дә үрнәк булган күрәсең, алар үзләре дә шигъри әсәрләр иҗат иткәннәр[2].

Гади халык, мөридләр арасында Гали Чокрыйның авторитет-шөһрәте шактый зур була, хәтта үзе исән вакытта ук аны «изге» дип атыйлар.

1889 елның көзендә Гали Чокрый авырып китә. Шул ук елның 4 октябрендә (иске стиль белән 21 сентябрь) Петербургта яшәүче мулла Хәмидулла Хәмитовка юллаган хатында: «Мәгәр үзем елдан зыйәдә (*артык*) мәриз (*авыру*) булып торам. Мәризем вәҗигыль-хәлкүмдер (*нык сызландыручыдыр*). Әмма әбдән важәм җәмиган сәхихтер (*бөтен гәүдәм тулаем сәламәттер*), фирашәдә (*урын өстендә*) дәгелмен... Мәгәр, кем, тәгам әд-дәкыйкны (*токмачлы ашны*) тәнәүвел кылып (*ашап*) булмый. Фәкать сөтле чәй илә тәнәггым кылып (*канәгатьләнеп*) торамын...», - дип яза.

1889 елның 24 декабрендә (иске стиль белән 10 декабрьдә) Гали Чокрый 61 яшенә җитеп фаный дөньядан бакый дөньяга күчә. Кабере – Иске Чокыр авылында.

**Иҗат мирасы**

Әдәбият тарихында Гали Чокрый бай һәм күпкырлы иҗат мирасы калдырган каләм ияләреннән санала. Шагыйрьнең Танып авылы Хәйрелзаман бине Габди мәдрәсәсендә үзен укыткан хәлфәсенә багышланган мәдхиясе һәм 1843 елда анасы Гөлбаһарның вафатыннан соң язылган мәрсиясе белән башланып киткән әдәби эшчәнлеге гомеренең соңгы көннәренә кадәр дәвам итә. Шушы еллар аралыгында язучы каләменнән дистәләрчә эреле-ваклы тезмә һәм чәчмә әсәрләр төшә.

Әдипнең тулы исем-фамилиясе – Мөхәммәдгали бине Габдессалих Киеков. Шулай да күпчелек әсәрләрен ул Чокрый, әл-Болгари, әл-Ирәктәви, әл-Бөреви, әл-Оренбурги, әл-Хаҗи, әл-Гари (гарәпчә – чокыр), әл-Вади (гарәпчә – үзән), Фәйз әл-Бари (гарәпчә – Аллаһының изгесе), Сарсази һәм башка тәхәллүсләр белән иҗат итә.

1860 елдан 1913 елга кадәр Гали Чокрыйның төрле зурлыктагы дистәдән артык әсәре, китап рәвешендә һәм аерым җыентыкларда, Казан, Уфа, Санкт-Петербург нәшриятларында дөнья күрә. Шундыйлардан **«Китабе тәҗвид»** *(«Тәҗвид китабы», 1860)*, **«Дөрре Гали»** *(«Гали энҗеләре», 1873)*, **«Шәмгъ эз-зыя...»** *(«Зыялылык шәме..., 1883)*, **«Замме назыйр»** *(«Охшаш өстәмәләр», 1888)*, **«Мәдхе Казан»** *(«Казанга мәдхия», 1889)*, **«Тәрхибе Рамазан»** *(«Рамазан аен сәламләү», 1903)*, **«Васыяте Мөхәммәдгали Чокрый»** *(«Мөхәммәдгали Чокрый васыяте»,1913)* һ.б. зур тиражлар белән басылып, халык арасында киң тарала. Әмма болар, диңгездәге бер тамчыдай, гаять бай һәм күпкырлы әдәби мирасның бик аз өлешен генә хасил итәләр. Авторның күпчелек әсәрләре бүген дә төрле китапханәләрдә, аерым кешеләр архивларында саклаучы кулъязма җыентыкларда кул тимәгән килеш кала бирә. Алар арасында шигырь белән язылган **«Әгъләм әл-һади»** *(«Күренекле шәхесләр хакында хәбәрләр»)*, **«Фәйзе-Гари»** *(«Гариның изгелекләре»)*, **«Фосуле әрбага»** *(«Елның дүрт фасылы»)*, прозада иҗат ителгән

---

[2] Татарстан Милли китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә 165 г. шифры белән теркәлгән җыентыкта Гали Чокрыйның шәкерте Мәмтай авылы имамы Әхмәдгали Гамәмеддиннең остазына атап язылган шигъри әсәре саклана. Әлеге ядкярдән авторның каләм белән оста гына эш итүен күрергә мөмкин.

**«Хаҗнамә»**, Ислам дине һәм суфыйчылыкның кайбер мәсьәләләренә багышланган **«Фасс әл-әхйар»** *(«Изгеләрнең йөзек кашы»)* кебекләре аеруча мөһим.

Югарыда искәртелгән гыйльми үзәкләрдә Гали Чокрыйның иҗат лабораториясендә булган төрле басма һәм үз кулы белән күчерелгән кульязма китаплары да байтак. Мәсәлән, Казан дәүләт университетының сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә аның Танып мәдрәсәсендә укыган вакытта ук күчереп язган гарәпчә «Тәһзибе мантыйки» *(«Логика укыту»)* рисаләсе бар. Татарстан Милли китапханәсендәге «Кыйссаи Йосыф» *(«Йосыф кыйссасы»)*, «Рәүнәкъ әл-Ислам» *(«Ислам диненең күркәм сыйфатлары»)* китапларының да югалган битләре язучы кулы белән тулыландырылган.

## Иҗтимагый-фәлсәфи карашлары

Гали Чокрыйның иҗат мирасы бай һәм күпкырлы. Ул – заманының алдынгы идеяләре белән янып, иҗатында шуларны гәүдәләндерүче язучы да, киң фикерле мәгариф эшлеклесе дә, халкының үткәне, киләчәге хакында уйланучы галим дә. Шулай да әдәбият тарихында әлеге каләм иясе гыйлем-мәгърифәткә дан җырлаучы әдип буларак мәгълүм.

Аның иҗатының күпчелек өлешен мәдхия, мәрсияләр тәшкил итә. «Шәмгъ эз-зыя...» *(«Шәм яктысы»)*, «Мәдхе Казан» *(«Казанга мәдхия»)* кебек басма китапларда, «Әгълам әл-һади» *(«Күренекле шәхесләр хакында хәбәрләр»)*, «Зәук әл-ләбиб» *(«Акыллылар зәвыгы»)*, «Китабе җәмгъ әл-ләваи» *(«Байраклар җыены китабы»)* кебек төрле кульязмаларда урын алган мондый әсәрләр, төгәллеккә дәгъва итмичә генә әйткәндә дә, өч мең ярымнан артык шигъри юлны берләштерә.

Хаклы рәвештә сорау туа: шагыйрь ни өчен иҗатының бу юнәлешенә зур игътибар биргән соң? Аңа җавапны каләм иясенең үз сүзләреннән үк табарга мөмкин. Шиһабеддин Мәрҗани, Шәмседдин Зәки, дамелла Габдулла бине Яхъя әл-Мәчкәрәви, Гали бине Сәйфулла Түнтәри кебек Чокрый данлаган «...мәзкүр кемсәнәләр йолдызлар кеби әгъла *(бөек)* мәкамдә *(урында)* мәхсүбләрдер *(саналучылардыр)* вә һәм сәйре кальби илә таләбе хикмәт *(күңел һәм хикмәт эзләү)* йулында гизгүчеләргә болар йолдызлар кеби һадилардыр *(юл күрсәтүчеләр)* диеб махсүбләрдер *(саналучылардыр...*». Димәк, шагыйрь, үз заманының алдынгы карашлы мәгърифәтчесе буларак, тулысынча кешеләргә белем бирүче, гыйлем нуры чәчүче шәхесләр ягында.

Гали Чокрыйның эстетик идеалы – зәвыклы һәм белемле, милләтне тәрәккъкый итү өчен, барлык көчен куеп, аңа хезмәт итүче фидакяр зат, укымышлы гади кеше. Шагыйрьнең үз әсәрләрендә Шәмседдин Зәки, Габделҗаббар бине Габдеррәхман әт-Тайсугани, Рәхмәтулла бине Гобәйдулла әл-Кизләви, Мөхәммәдхарис Биктимеров һәм башка тарихи шәхесләрне мактавы да шул хакта сөйли.

Әдәбият тарихында Гали Чокрый һәм Акмулла (1831-1895) Шиһабеддин Мәрҗанигә атап мәдхия, мәрсия язучы беренче шагыйрьләр буларак мәгълүм. Чокрыйның күләме ягыннан зур булмаган әлеге әсәре 1883 елда Казанда нәшер ителгән «Шәмгъ эз-зыя...» китабында урын алган.

Автор үз героеның затлы нәсел-нәсәбен мактап, аны «шөһрәт һәм бөек фикер иясе», «күп фәннәрне, хикмәтләрне укып» «төрле мәсәләләрне ачып рисаләләр язучы», «күп дәлилләрне белүче» олы галим буларак телгә ала, аны калганнарга үрнәк шәхес итеп куя. Әлеге фикер строфа саен кабатланып килүче «һадилар кем безем саздыр» *(«безгә дөрес юл күрсәтүче»)* рәдифе ярдәмендә шигъри текстның башыннан алып ахырына кадәр ассызыкланып килә.

Бу мәдхиядән тыш Чокрыйның «Манзумате Гали бине Салих әл-Чокрый әл-хаҗи фи мәдхе китаб «Назурәт әл-хак» вә мусаннифиһи галә-л-итлак» *(«Гали бине Салих әл-Чокрый әл-Хаҗиның «Хакыйкатьне күзәтү» китабын һәм аның авторын тулысынча (яклап) мактаган шигыре»)* исемле әсәре дә Шиһабеддин Мәрҗанине һәм аның мәгърифәт өлкәсендәге эшчәнлеген куәтләүгә корылган.

Шагыйрь үз героен романтик югары пафос, мул буяулар белән тасвирлаудан читләшә бара, аны реаль чынбарлыктан аермыйча, конкрет эшчәнлегенә бәя бирү аша сурәтләүгә таба йөз тота.

Гали Чокрый, гади халыкка һәм бары тик дини гыйлемнәр белән генә канәгать калган муллаларга үрнәк шәхес буларак, Мәрҗанине аерып күрсәтә. Автор үз героен хакыйкать өчен көрәш юлында акыл һәм гыйлем көченә таянып гамәл кылучы шәхес итеп сурәтләү аша мәгърифәтчелек идеалын гәүдәләндерә.

Гали Чокрый әсәрләрендәге надан руханилардан ачы көлү, татар мөселман җәмгыятендәге төрле әхлакый бозыклыкларны фаш итү мотивы һәм камил инсан турындагы этик-эстетик карашлар җыелмасы да турыдан-туры акыл, гыйлем төшенчәләре белән бәйле. Бу уңайдан язучының әдәбият фәнендә авторы Сөләйман Бакырганый дип исәпләнүче «Ахыр заман» китабына нәзыйрә рәвешендә язылган «Замме назыйр» *(«Охшаш өстәмәләр»)* ядкяре игътибарга лаек.

Югары мораль-этик сыйфатларның теләсә нинди җәмгыять, милләт үсеше нигезендә ятуын шагыйрь яхшы аңлый. Шуңа үз чоры җәмгыятенең әхлакый бозыклыгы – әдипне борчыган мөһим мәсьәләләрнең берсе.

Илдә наданлык, ваемсызлык хөкем сөрә, халыкның күпчелеге комсызланып мал-мөлкәт җыю белән, дөнья эше белән мәшгуль, әмма «ата-ана хидмәтилә *(хезмәте илә)*... йахуд, милләт хидмәтилә мәшгулъ ирмәс». Игенчеләр «ызан сөреб, юллар сөреб тәүсигъ әйләр *(киңәйтер)*», «тегермәнгә, йортка, җиргә малын түгәр», әмма гөшер зәкяты турында бөтенләй онытыр, «мәдрәсәгә бер тиен бирсә, гүйә үләр». Базарларда хәмер тулган, «күп җаһилләр хәмер эчкәй, зина кылгай». Мондый җәмгыятьнең киләчәге юк, шагыйрьнең үз сүзләре белән әйткәндә, аның өчен «кыямәт көн кариб *(якын)* торыр». Әдип фикеренчә, бу күренешнең нигезендә җаһиллек, наданлык ята:

Гавам эчрә наданлык мәншүр улды *(таралды)*,
Уку бары язар өчен мәнзур булды *(искә алынды)*,
Гыйлем берлә гамәлләрдә мәнфур улды *(аерылды)*, -
Андыйн артык тәкый гаҗәп таңнары бар
*(Аннан артык таң калырлык җирләре бар)*.

Гали Чокрый, урта гасыр мәгърифәтчелек романтизмына хас булганча, гыйлемне әхлакны тазарту чыганагы буларак күзаллый, әлеге төшенчәләрнең үзара бәйләнешен раслый. Бу яктан аны әл-Газали карашларын, Г.Утыз Имәни традицияләрен дәвам итүче дип билгеләргә мөмкин, әмма әдипнең гыйлем төшенчәсен киң планда һәм дини һәм дөньяви гыйлем мәгънәләрендә аңлавы аны Яңа чор мәгърифәтчеләре рәтенә күтәрә.

Гали Чокрый каләменнән төшкән башка әсәрләрнең дә уңай геройлары – халык язмышын, аның киләчәген кайгыртучы галим-голәмәләр, тарихи шәхесләр. Әдип «Әгълам әл-һади» *(«Күренекле шәхесләр хакында хәбәрләр»)*, «Зәук әл-ләбиб» *(«Акыллылар зәвыгы»)*, «Китабе җәмгъ әл-ләваи» *(«Байраклар җыены китабы»)* кебек кулъязма җыентыкларда урын алган күпсанлы мәдхия-мәрсияләрендә татар әдәбияты өчен зур идея-эстетик мәгънәгә ия уңай геройларның бай галереясен тудырды.

1883 елда «Әгълам әл-һади»ның беренче өлеше «Шәмгъ эз-зыя...» исеме белән Казанда аерым бер китап булып басылып чыга. Кырык битле әлеге җыентыкта Вәлид бине Мөхәммәд әл-Әмин әл-Каргалы, Хәбибулла әл-Орыви, Җәгъфәр бине Габди әл-Болгари, дамелла Габдулла бине Яхъя әл-Мәчкәрәви, Гали бине Сәйфулла Түнтәри, мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев, Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрлебаши, Шиһабеддин Мәрҗани кебек укымышлы затларны һәм аларның эшләрен данлаган шигъри әсәрләр урын алган. Боларда әдип әлеге шәхесләрнең җәмгыять, милләт файдасы өчен эшләгән игелекле эш-гамәлләре хакында фикер йөртә, аларны «дәхи милләткә гам *(тулысынча)* файда кылган ирләр» дип атый.

Бу урында М.В.Ломоносов, А.П.Сумароков, Н.Г.Державин кебек XVIII йөз рус классицизмы вәкилләренең Петр I, Екатерина, Елизавета сыман патшаларга атап язылган одалары белән параллель уздыру урынлы булыр иде. Аларның уңай герое – халык

алдында узенең бурычын тоючы, гражданлык, патриотик хисле сугышчылар, полководецлар, мәгърифәтле монарх, төп фикере – ил, милләт язмышы хакында уйланулар.

XIX гасыр татар шигъриятендәге мәдхия-мәрсияләрдә дә милләт язмышы, аның киләчәге өчен борчылу төп мотивларның берсе. Әмма татарның үз дәүләтчелеге булмау сәбәпле, рус одаларындагы милләт маягы – «мәгърифәтле монарх» урынын үз укымышлы галим-голәмәсе, алдынгы карашлы дин эшлеклеләре алды. Гали Чокрыйның дамелла Габдулла бине Яхъя әл-Мәчкәрәвине рус патшалары белән бер рәткә куеп сурәтләве дә шул хакта сөйли булса кирәк.

Шагыйрьнең тормыш фәлсәфәсе, яшәү мәгънәсе турындагы уйлары да турыдан-туры милләт, халык язмышы төшенчәләре белән бәйле. Бу уңайдан әдипнең «Шуюхе Болгар» (*«Болгар шәехләре»*) исемле шигъри әсәре игътибарга лаек. Биредә авторның XIX гасыр татар укымышлыларын Болгар шәехләре дип, аларның алтын силсиләсен Идел Болгарстаны чорына, легендар зат – Айдар хан заманнарына илтеп тоташтыруы болгар-татар тарихы барышын эзлекле һәм бербөтен итеп күзаллавы хакында сөйли.

Бу ханнар вактында әүвәл, бу Болгар булды бик әҗмәл *(иң матуры),*
Шәехләр күб иде әҗмәл *(бик күркәм)*, һадилар кем безем саздыр.
Айдарның дәүләте бардыйн шәехләр килде күб дардин *(илдән),*
Үтеб китәр дә Болгардин, һадилар кем безем саздыр, -

дип яза шагыйрь.

Гали Чокрый өчен Болгар нәкъ менә укымышлы, зыялы затлар күплеге белән, гыйлем-мәгърифәт учагы булуы белән данлыклы, җыеп әйткәндә, татар мәдәниятенең бишеге булганга кадерле. Шуңа күрә әлеге каләм иясе Болгар иленең галим-голямәсен, шәехләрен зиннәтле киемнең гәүһәр ташлары белән чагыштырып, болай ди:

Әгәр атлас исә Болгар, җәваһир миследер болар,
Һәр әтрафә сачелделәр, һадилар кем безем саздыр.

Болгар темасы белән бәйле тарихи мотивлар Гали Чокрыйның «Мәдхе Казан» *(«Казанга мәдхия»)*, «Тәварихе Болгария йәки тәкърибе Гари» *(«Болгар тарихы яки Гариның якынча аңлатмалары»)* һәм башка әсәрләрендә дә дәвам итеlә, иҗатының лейтмотивына әверелә.

Бу хезмәтләрендә дә әдип, үз элгәреләре кебек үк, болгар-татар тарихын бербөтен итеп күзаллый. Әйтик, «Мәдхе Казан» әсәре Казан шәһәрен сурәтләү белән башланып китсә дә, «Менә шәһре Казанда(н) күб мөкаддәм *(элгәре)* шәһре Болгар хуб» дип, лирик чигенеш аша, автор укучыны Болгар чорларына алып килә. Тик биредә инде Идел буе Болгарстаны турында түгел, ә Батый хан җитәкчелегендә 1236-37 елгы монгол яулары тарафыннан басып алынганнан соң Алтын Урда дәүләтенең бер өлеше булып киткән Болгар олусы хакында сүз бара. Әдип үзе турыдан-туры бу хакта искәртмәсә дә, әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар моның шулай икәнлеген ачык раслый.

Шагыйрь бу дәүләтне Ислам мәдәнияте, белем-мәгърифәт учагы, барча мөселманга таяныч ноктасы, ягъни бар яктан да тәрәккъый ил итеп тасвирлый. Бу дәүләт халкының үзара дус, тату яшәгәнлеген ассызыклап, әдип тынычлыкка дан җырлый. Төрле сугышларга, баскынчыларга карата аның нәфрәте чиктән ашкан.

Гали Чокрый дан-шөһрәте еракларга киткән әлеге илнең юкка чыгу сәбәпләре турында уйлана, Аксак Тимер яуларын Болгарны җимерүче көч итеп күрсәтә. Аның үзен, романтикларча арттырып, «йөзе-күзе чагыйр» *(кылый)*, «фасыйк» *(азгын)*, «фаҗир» *(бозык)* зат дип сурәтли, «ләимнәрдән ләим тагый» *(канәчкечләрдән канәчкеч тиран),* «багый» *(юлбасар)* дип белдерә.

Татар әдәбияты тарихында Аксак Тимер алып барган сугышларны тәнкыйтьләү, аны Болгар дәүләтен җимерүче итеп сурәтләү урта гасырлардан ук килә. Гали Чокрый да үз элгәрегеләре Мөхәммәд Баззази, Сәйф Сараи, Әхмәд Үргәнчи, Мөхәммәд Әмин кебек бу традицияләрне дәвам итә, Аксак Тимерне «татарны хараб кылган», илне җимергән

«хунхар» *(канэчкеч)*, хәтта барлык мөселман дөньясына, ислам диненә зарар салучы зат итеп тасвирлый.

Шагыйрь Болгар халкының Аксак Тимер яуларына каршы батырларча көрәшен шактый тулы һәм җанлы итеп сурәтләү аша татар халкының шул чордагы авыр хәләтен шанлы тарих, газаплы вакыйгалар фонында оста итеп ачып бирә. Биредә илсез-җирсез калган татар халкының аянычлы язмышын тасвирлау белән бергә, авторның әлеге вакыйгаларга мөнәсәбәттә моң-зары, ачы хәсрәте дә үзен ачык сиздерә.

Шагыйрь фикеренчә, Аксак Тимер ни кадәр рәхимсез рәвештә Болгарга яу чапмасын, татар халкын, аның дәүләтчелеген юк итә алмаган. Болгар ханы ил өстенә килгән хәсрәтләрдән вафат булса да, аның эшен ике улы дәвам иткән. Алар яңа урында, Казансу елгасы буенда янәдән шәһәр корганнар. Әсәрнең

Дәхи Болгар ханы анда һәлак булган бу әхзанда(н) *(кайгылардан)*
Ике углы калыб анда Казансуга карар саздыр, -

дигән юллары XIX гасырда Каюм Насыйри тарафыннан язып алынган һәм календарьларының берсендә нәшер ителгән «Казан бәете»нең түбәндәге дүртьюллыгы белән аваздаш дияргә мөмкин:

Тарихе йите йөздә килде Тимер Болгарга,
Габдулла ханның кулындин Болгар шәһәрен алдия.
Ул бүлекнең суңында, Казан суы буенда,
Ике углы калубән Казан шәһәрен салдыя.

Бу ике әсәрдә дә сүз Алтын Урда хөкемдары Үзбәк ханның (?-1342) оныгы Габдулла хан (якынча 1340-1370) турында бара булса кирәк. XVIII йөздә язылган тарихи елъязмалар, риваятьләр буенча, Аксак Тимер Болгарны җимергәннән соң, Габдулла ханның ике улы Галимбәк белән Алтынбәк Иске Казан каласына нигез сала (кайбер чыганакларда Чирмешән буенда Бюлюмар яисә Төмән ханлыгы башкаласы Чимге-Тура шәһәрләре дип тә күрсәтелә).

XV гасырның беренче чирегендә Алтын Урда һәм аның бер өлеше саналган Болгар тәмам таркала һәм сәяси, икътисади, мәдәни үзәк тулысынча Казан ханлыгы кулына күчә. Алга таба үз әсәрендә Гали Чокрый Казанның да фаҗигале язмышка дучар булуын искәртә, аның да дошманнар тарафыннан җимерелеп, күп михнәтләр кичерүен ассызыклап үтә:

Рәхим рахманга йалбарыб, ватан төзгән кайа барыб,
Аны да әгъда *(дошманнар)* актарыб, ничә михнәт илән саздыр.
Йәнә әһле Казан хандин калыб мәхрүм һәм аутандин *(ватаннардан)*
Йаңа йиргә күчеб андыйн, ничә михнәт гайан саздыр *(билгеледер)*.

Бу уңайдан Чокрыйның әлеге әсәре XVI йөз татар шагыйре Шәрифинең «Зәфәрнамәи вилаяте Казан» *(«Казан өлкәсенең җиңүе»)* исемле әдәби ядкяре белән дә аваздаш дияргә мөмкин. Ике әсәр дә, Казан каласын мактау белән бергә, бөтен татар халкының батырлыгы алдында баш ию булып та яңгырый.

XIX йөздә Казан мөселман дөньясының гына түгел, Европа илләре өчен дә сәяси, икътисади һәм мәдәни үзәкләрнең берсенә әверелә бара. Табигый ки, бу әлеге чор әдәбиятында да чагылыш таба, Казанга багышлап әсәрләр иҗат ителә. Еш кына аларда Казан теге яки бу вакыйга уңае белән генә түгел, ә аерым бер әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелеп сурәтләнеш таба.

XIX йөзнең соңгы чиреге-XX гасыр башында язылган Гали Чокрыйның «Мәдхе Казан» (1889), Мөхәммәд Йосыфның «Казан голямәсе, мөдәррис вә мәсаҗиде хакында» (1894) әсәрләре, Тукай каләменнән төшкән «Пар ат» (1907), «Печән базары яхуд яңа Кисекбаш» (1908), «Казан» (1913) кебек шигъри ядкярләр – әнә шундыйлардан.

Шунысы мөһим: югарыда телгә алынган шигъри ядкярләрдә Казан каласы әдәби фон вазифасын үтәсә, Гали Чокрыйның «Мәдхе Казан» әсәрендә аерым бер әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелә. Автор биредә, илһамланып, Казанның тышкы күренешен, табигатен тасвирлый, андагы йорт-җирләрнең төзеклегенә, мәчетләренең күплегенә хәйран кала,

шушы гүзәллекне тудыручыларның эш-гамәлләренә, аларның инсафлылыгына, олы күңелле булуларына соклануын белдерә. Әмма шагыйрьнең соклануы бер яклы гына түгел, ул әлеге матурлыклар артында үз халкының чиксез моң-сагышын, ачы хәсрәтләрен дә ачык тоя. Автор укучыга «Гыймарәт форсаты йөз сал» *(йортларын, төзелешләрен күр)* алар барысы да халыкның «михнәти», газаплы язмышын чагылдыралар ди.

Гали Чокрый сүз белән сурәт ясауда географик детальләрдән оста файдалана. Әсәрдәге «ләтаиф әүсафы мәрсүм *(матур сыйфатлары билгеле)*, Кабан күл яры да мәнзум *(чиста, тәртипле)*», «Бишбалта, Порхавой Казан хөкмендә гали *(югары)* җай» кебек тасвири сыйфатлар аша шәһәр пейзажы туа.

Шагыйрь Казанның йортларын, мәчетләрен күздән кичерә, аларның күплегенә, матурлыгына таң калып, «тәмам зиннәт илә саздыр» дип яза. Мәчетләрнең күпчелеге санап үтү рәвешендә искә алынса, Хан мәчетенә аерым шигъри юллар багышланган:

Йәнә Хан мәсҗеде дә бар бу иске бистәдә әй, йар,
Манарасы гали, азһар, васыйф тәшһир илә саздыр
*(Манарасы һәр җирдән күренә, мактап сөйләүгә лаек)*.

Шул рәвешле, әлеге архитектур корылма Казанның идея-эстетик йөзен билгеләүче символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Петербургтагы 1782 елда Фальконе тарафыннан иҗат ителгән Бакыр җайдак (Медный всадник) сыны рус әдәбиятында А.Пушкин, Н.Огарев, А.Блок, В.Брюсов һәм башка бик күп язучылар әсәрләрендә шәһәрнең архитектур һәм идея-эстетик сыйфатларын чагылдыручы символик образ булса, Чокрыйның «Мәдхе Казан»ында сурәтләнеш тапкан Хан мәчете дә шундый ук вазыйфаны үти дияргә мөмкин.

Шагыйрь Казанны матурлыкның сәнгатьчә югары дәрәҗәсенә җиткереп эшләнгән йортлары, зиннәтле мәчетләре өчен генә данламый. Ул бу корылмаларны шушында яшәгән халыкның тырыш хезмәт нәтиҗәсе итеп күзаллый. Әдип өчен әлеге шәһәр – тере социаль организм. Казан «ләбибләр... әдипләр... табиблар күплеге берлә», алар тудырган гүзәл эшләр белән бар җиһанга мәшһүр кала.

Татар халкының тырышлыгы, эш-һөнәргә осталыгы турында сөйләгәндә әсәр тукымасына этнографик элементлар да уңышлы кертеп җибәрелә. Әдип фикеренчә, казанлылар тарафыннан тегелгән кием-салым, калфак, читек, башмак галәм халкы алдында мактауга лаек.

Шагыйрьнең: «Йәнә анда хатын-кызлар тегү-чәнчү нәкыш дәйар *(тегү-чигүдә осталар)*», - дип татар халкында чигү сәнгатенең алга киткәнлегенә игътибар итүе дә очраклы күренеш түгел. Әлеге һөнәрнең ерак тамырлары хакында «Әдәби сүзлек»тә болай диелгән: «Татар халкының чигү сәнгате күп гасырлар буена өзлексез үсә-камилләшә килгән. Аның традицияләре дә безнең бабаларыбыз Идел буе болгарларына һәм Казан ханлыгы чорына барып тоташа. Археология материалларына караганда, мәсәлән, ефәк җепләр белән алтынлап һәм көмешләп чигү ысулы Болгар халкы арасында киң таралган булган» [235]. Димәк, бу алым авторга укучы күңелендә болгар-татар тарихи дәвамчанлыгының өзлексезлеген тагын бер кат искә төшерергә мөмкинлек бирә.

Татар халкының милли йөзен, характер-сыйфатларын аның этник киемнәре, билгеләре аша ачарга омтылыш – XIX гасыр шигърияте өчен чагыштырмача яңа күренеш. Бу – әдәбиятның идея-эстетик сыйфаты ягыннан яңа баскычка күчә бару дәлиле. Гали Чокрый кулланган этнографизм алымын соңрак башка татар язучылар да үз итә. Бу бигрәк тә, әдәбиятыбыз классигы Гаяз Исхакый иҗатында тотрыклы традициягә әверелә.

Җыеп әйткәндә, «Мәдхе Казан» әсәрендә Казан аерым бер шәһәр буларак кына тасвирланмый, ә татар халкының үткәнен һәм киләчәген символлаштыручы, милли йөзен билгеләүче образ дәрәҗәсенә күтәрелеп сурәтләнелә. Биредәге тарихи мотивлар әдипнең милли һәм ватанпәрвәрлек хисләре белән симбиоз рәвештә үрелеп бара. Автор Казанны Болгар дәүләтенең тулы хокуклы варисы буларак, ягъни болгар-татар тарихын букбөтен процесс итеп күзаллый. Әлеге фикер әсәрнең:

Мәгәр Болгарны һәб гамләр *(барча халык)* тәмам империя диб аңлар,
Тәмам Болгарда нәләр бар – күбе монда назар саздыр *(чагыладыр)*, -

дигән юллары аша да ачык аңлашыла. Казан каласын Болгар шәһәрләре белән чагыштыру рәвешендәге «Берәрсе киләме парга, кеме Казан мисал саздыр?!» *(Казан белән тиңләшерлек)* риторик соравында шагыйрьнең үз ватаны өчен горурлык хисен, ватанпәрвәрлек мотивларын да аермачык тоярга мөмкин.

Бу фикерләрен язучы үзенең башка шигырьләрендә дә дәвам итә. Мәсәлән, бер әсәрендә ул туган илгә мәхәббәтен, кыска, әмма тәэсирле рәвештә: «Дийары горбәтә *(чит җирләргә)* дөшеб, кеше шаһ улмасы даим, Кирү кәнди дийарында *(үз илендә)* гидай улмасына йитмәз», - дип, афористик фикергә корылган шигъри юллар аша белдерә.

Гали Чокрый үз гомерендә дүрт тапкыр хаҗ кыла. 1872-73 елгы сәфәреннән соң авылдашлары үтенече буенча зур күләмле «Хаҗнамә» әсәрен иҗат итә. Әдипнең туган йортыннан башланган хаҗ сәфәре аның Казан, Түбән Новгород, Мәскәү, Одесса, Истанбул, Искәндәрия, Җиддә шәһәрләре аша поезд һәм кораб белән Мәккә, Мәдинә калаларына килүе, анда хаҗ кылганнан соң, Кара диңгез, Азов диңгезе, Дон, Идел, Чулман елгалары буйлап кире туган якларына кайтуы белән тәмамлана. Авторның әлеге сәяхәт барышында күргәннәре, уй-кичерешләре «Хаҗнамә»гә әдәби материал булып ята.

Биредә Гали Чокрый гади күзәтүче буларак кына чыгыш ясамый, киресенчә күргән һәр хәл-вакыйгага үзенең актив мөнәсәбәтен белдереп бара. Әдип Россияне икътисади һәм техник яктан нык алга киткән ил итеп тасвирлый, аның байлыкларына, тәртипләренә соклануын яшерми. Гарәп илләрендә хөкем сөргән кайбер тәртипсезлекләргә каршы Россияне үрнәк итеп: «Мәмләкәте Русийәдә булган низамлар *(тәртипләр)* чаклы низамлар бер йирдә дә булмаса кирәктер... бөйлә ихласы вә гайрәтле хезмәтләре буенча Русийә мәмләкәте бик күб мәмләкәтдин баерак вә мәгъмүррәк *(төзегерәк)* вә мәшһүррәк булгандыр», - дип яза.

Автор фикеренчә, аның туган ягы – Идел-Урал төбәге дә әлеге дәүләтнең аерылгысыз бер өлеше. Россияне «безем Русийә», ә идарә итүче патшаны «Русийәнең мөстәкыйль сәрдәре *(җитәкчесе)* вә муштәһир шәһрияры шаһымыз вә солтанымыз» дип билгеләве бу фикернең хаклыгын раслап тора.

Гали Чокрый XIX гасырда татар иленең Россия дәүләте белән бергә тәрәкъкый итү мөмкинлеген дә кире какмый. Бу хакта галим Михаэль Кемпер болай дип яза: «Шул ук вакытта Чокрый сәяхәтнамәсендә үзенең яңа Россия алгарыш хәрәкәтенә катнашуын искәртә, яңа мөселман культурасының рус җәмгыятенә карата булган изоляцияне киметә алырдай хәлдә икәнлегенә ишарә ясый» (Тәрж. – И.Г.) [392].

Димәк, Гали Чокрый тәрәкъкыять мәсьәләләрендә толерантлык принципларына таянып, XIX йөз татар җәмгыяте өчен демократик үсеш юлын тәкъдим итә.

Күренә ки, XIX гасырның күренекле руханые, әдибе, галим-мәгърифәтчесе Гали Чокрый катлаулы һәм драматик тормыш юлы үтә. Аның тәрҗемәи хәлен һәм әдәби мирасын нинди дер берьяклы һәм абстракт өлгеләр белән генә үлчәп булмый. Иң беренче чиратта, ул – үз тормышы, иҗаты белән татар яшәешен заман таләпләренә якынайту өчен җан аткан фидакяр зат. Мөдәррислегендә дә, имамлыгында да, әдип-галимлек сыйфатында да ул шушы принципларга таянып эш итә. Аның иҗатының идея-эстетик эволюциясен, әсәрләрендәге иҗтимагый-фәлсәфи карашларын да үз чорының тарихи таләпләре аша күзәткәндә генә тулаем аңларга һәм төшенергә мөмкин.

Әдәбият:


1. Рәми И.Г. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.
2. Рәмзи Морад. Тәлфикъ әл-әхбар вә тәлкигъ әләсар фи вакаигъ Казан вә Болгар вә мүлүк әт-татар. II китап. – Казан, 1908.
3. Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере. Икенче басма. – Казан: Татарстан матбугаты һәм нәшрияты комбинаты, 1925.
4. Kemper M. Sufis und Gelehrte in Tatarien und Baschkirien, 1789-1889. – Berlin, 1998.


***Филол. фән. канд. Гомәров Илһам***